**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**16нчы май, 2022 ел** **№ 163**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә (13.10.2017 №168, 28.03.2018 №202, 11.07.2018 №226, 31.08.2018 №238, 17.04.2019 №287, 22.05.2020 №371 карарлары редакциясендә), кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм комиссия (алга таба - Бердәм конкурс комиссиясе) төзергә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен (алга таба - Бердәм аттестация комиссиясе) төзергә.

3. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм конкурс комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы 1 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе турында нигезләмә һәм аның составы 2 нче кушымта нигезендә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә, Биектау муниципаль районы Советы кадрлар бүлегенә Бердәм конкурс комиссиясе һәм Бердәм аттестация комиссиясе эшчәнлеген законнарда билгеләнгән тәртиптә оештыру-техник яктан тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Кадрлар сәясәте» бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16нчы майның
163нче номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә Бердәм конкурс комиссиясе составы**

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Шакиров<br>Әнәс Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары |

*Комиссия рәисе урынбасарлары:*

| | |
|---|---|
| Афанасьев<br>Алексей Павлович | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |

*Комиссиянең җаваплы секретаре:*

| | |
|---|---|
| Сабирова<br>Вероника Александровна | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар бүлеге башлыгы |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Шәйдуллин<br>Дамир Фәрит улы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Сабирҗанов<br>Марат Таһир улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының коррупциягә каршы көрәш буенча муниципаль район башлыгы ярдәмчесе |
| Таҗиев<br>Илдар Илгизәр улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы |
| Мөстәкыймова<br>Эльмира Фиргать кызы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының оештыру бүлеге башлыгы |
| Сабирова<br>Гүзәл Фәрит кызы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ эшләр идарәчесе |

| | |
|---|---|
| Минһаҗев<br>Салават Марат улы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе |
| Сабирҗанов<br>Ринат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Әхмәтҗанов<br>Нияз Камил улы | район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Медведева<br>Нина Григорьевна | бәйсез эксперт - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ директоры |
| Газизуллина<br>Лениза Шамил кызы | бәйсез эксперт - «Татарстан Республикасы Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16нчы майның
163нче номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе составы**

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Шакиров Әнәс Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары |

*Комиссия рәисе урынбасарлары:*

| | |
|---|---|
| Афанасьев Алексей Павлович | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |

*Комиссиянең җаваплы секретаре:*

| | |
|---|---|
| Сабирова Вероника Александровна | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар бүлеге башлыгы |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Шәйдуллин Дамир Фәрит улы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Сабирҗанов Марат Таһир улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының коррупциягә каршы көрәш буенча муниципаль район башлыгы ярдәмчесе |
| Таҗиев Илдар Илгизәр улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы |
| Мөстәкыймова Эльмира Фиргать кызы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Аппаратының оештыру бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Сабирова<br>Гүзәл Фәрит кызы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ эшләр идарәчесе |
| Минһаҗев<br>Салават Марат улы | «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе |
| Сабирҗанов<br>Ринат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Әхмәтҗанов<br>Нияз Камил улы | район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Медведева<br>Нина Григорьевна | бәйсез эксперт - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ директоры |
| Газизуллина<br>Лениза Шамил кызы | бәйсез эксперт - «Татарстан Республикасы Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |

1нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16нчы майның
163нче номерлы
карары белән расланды

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНДА МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕҢ ВАКАНТЛЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮГӘ КОНКУРС УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә белән Биектау муниципаль районы юридик заты (алга таба - муниципаль орган) хокукларына ия булган җирле үзидарә органнарында, аларның структур бүлекчәләрендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыруның тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

2. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс (алга таба - конкурс) гражданнарның муниципаль хезмәткә бертигез дәрәҗәдә үтә алу хокукына, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

4. Җирле үзидарә органнарында конкурс вакантлы (муниципаль хезмәткәр биләмәгән) муниципаль хезмәт вазыйфасы булганда, җирле үзидарә органы, муниципаль орган җитәкчесе яисә җирле үзидарә органы исеменнән яллаучы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат карары буенча игълан ителә.

5. Конкурс үткәрелми:

а) сроклы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

б) муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәве медицина бәяләмәсе нигезендә мөмкин булмаган очракта муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләп куелганда, биләгән вазыйфасы кыскартылу, җирле үзидарә органы структурасын үзгәртеп оештыру, бетерү яисә үзгәртү очрагында;

в) конкурс нигезендә төзелгән кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәр (граждан) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганда.

6. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

а) муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләнгәндә җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча;

б) муниципаль хезмәтнең аерым муниципаль вазыйфаларына билгеләп куелганда, вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле.

7. Конкурста катнашу хокукына, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт

турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясында муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр буларак билгеләнгән шартлар булмаганда, 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килгән Россия Федерациясе гражданнары ия.

Муниципаль хезмәткәр конкурс уздыру чорында аның нинди вазыйфа биләвенә карамастан, конкурста гомуми нигезләрдә катнашырга хокуклы.

8. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен Биектау муниципаль районы башлыгы карары белән Бердәм конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә. Күрсәтелгән акт белән Комиссия составы билгеләнә.

Комиссия составына җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук бәйсез экспертлар сыйфатында чакырыла торган башка оешмалар вәкилләре керә.

9. Комиссия составы Комиссия кабул иткән карарга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

10. Комиссия комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннан һәм Комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаганда башкара.

Комиссия секретаре Комиссия утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә, Комиссия әгъзаларына утырыш чакырылу турында хәбәр итә, Комиссия әгъзаларына көн тәртибе турында хәбәр итә, гаризаны, документларны кабул итә һәм терки, Комиссия беркетмәсе проектын әзерли, конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында кандидатларга хәбәр итүне тәэмин итә, Комиссия рәисе йөкләмәсе буенча башка функцияләр башкара.

11. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Ачык тавыш биргәндә тавышлар тигез булганда Комиссиянең рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

12. Конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

Конкурс уздырганда Комиссия кандидатларны алар тапшырган белем алу, муниципаль, граждан яисә башка дәүләт хезмәте узу, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук кандидатлар дәгъва кылган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча индивидуаль әңгәмәне, анкетаны, төркемле дискуссияләр уздыруны, реферат язуны яисә тест үткәрүне дә кертеп, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә Комиссия муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән, әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи инструкция нигезләмәләреннән,

шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

13. Муниципаль орган конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерүне «Дәүләт хезмәте» мәгълүмат порталында https://gossluzhba.gov.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча, шулай ук конкурс уздыру турында мәгълүматны Интернет челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында конкурс уздыру көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча урнаштыра.

Конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан ителгән белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы исеме;

б) әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләр;

в) документлар кабул итү урыны һәм вакыты;

г) күрсәтелгән документлар кабул ителә торган вакыт, шулай ук конкурс турында төгәл мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта);

е) конкурс уздыру датасы һәм вакыты.

14. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы Комиссиягә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) Комиссия рәисе исеменә әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә шәхси гариза;

б) фотография, автобиография кушымтасы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча кулдан тутырылган һәм имзаланган анкетаны;

в) паспорт яисә аны алыштыручы документ күчермәсен (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемне, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (хезмәт (эш) беренче тапкыр гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш) яисә гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар;

һөнәри белем турында, шулай ук гражданның теләге буенча - эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яисә кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем бирү турында документларның күчермәләре;

д) мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсен;

е) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;

ж) хәрби исәпкә алу документлары - хәрби хезмәткә бурычлы затлар өчен һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

з) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга киртә булган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән рәвештә мондый авырулар исемлегендә каралган авыруы булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

и) конкурс уздыру елыннан алдагы календарь ел өчен гражданның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук конкурс уздыруга кадәрге елда керемнәре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне җирле үзидарә

органнарының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән форма буенча белешмәләр, - граждан җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлекләре белән каралган, муниципаль хезмәткәрләр аларны биләгән очракта әлеге белешмәләрне тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфаларына кергәндә;

к) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы граждан һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны алдагы өч календарь елда урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында белешмәләр;

л) гамәлдәге законнарда каралган башка документлар.

15. Гариза биргән затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

16. Конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр гаризаны Комиссия рәисе исеменә җибәрә. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте аңа конкурста катнашу өчен кирәкле документларны алуны тәэмин итә.

17. Граждан (муниципаль хезмәткәр) биләүне дәгъвалаган муниципаль хезмәт вазыйфаи бурычларын үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса, гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) ризалыгы белән аны дәүләт серен һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләргә кертүне рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Граждан тарафыннан Комиссиягә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш.

18. Граждан (муниципаль хезмәткәр) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле конкурста катнашуга, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә рөхсәт ителми.

Конкурста катнашуга кертелмәгән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылу әлеге карарга законнар нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире кайтара ала.

19. Тәкъдим ителгән документларны Комиссия секретаре кабул итә. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән документлар комиссиягә «Дәүләт хезмәте» мәгълүмат порталында https://gossluzhba.gov.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә тапшырылалар.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә җитди сәбәпләрсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларны җитди сәбәпләр буенча вакытында тапшырмаганда, аларны тулы күләмдә тапшырмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләре бозылганда, комиссия рәисе карары белән аларны кабул итү сроклары күчерелергә мөмкин.

Конкурс гаризалар бирү срогы тәмамланган көннән алып 10 көн эчендә уздырыла.

20. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы

гражданнар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерү барышында федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүенә каршы килә торган хәлләр ачыкланган очракта, аңа конкурста катнашудан баш тарту сәбәпләре турында Комиссия тарафыннан язма рәвештә хәбәр ителә.

21. Конкурс уздырганда кандидатларга законнар нигезендә хокукларның тигезлеге гарантияләнә.

22. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә Комиссия конкурста катнашуга кандидатларны кертү турында карар кабул итә. Кандидатларны тикшерү һәм конкурс нигезендә сайлап алу Комиссия утырышларында гамәлгә ашырыла.

23. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе кабат конкурс уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

24. Комиссия утырышы кимендә ике кандидат булганда уздырыла.

25. Конкурс процедураларын уздыру нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кандидат муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килә;

2) кандидат муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килми;

3) кандидат кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителде.

26. Комиссия карары кандидат булмаганда кабул ителә.

27. Комиссиянең карары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

28. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча яллаучы вәкиле (эш бирүче) конкурста җиңүче белән хезмәт шартнамәсе төзи һәм аны муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгели.

Әгәр комиссия муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган кандидатны муниципаль органның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итсә, күрсәтелгән зат ризалыгы белән аны әлеге органның кадрлар резервына кертү турында муниципаль орган акты муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркем муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләү өчен чыгарыла.

29. Конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә ул тәмамланган көннән соң бер ай эчендә хәбәр ителә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат «Дәүләт хезмәте» мәгълүмат порталында https://gossluzhba.gov.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырыла.

30. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва кылучылар һәм конкурста катнашкан кандидатлар документлары конкурс тәмамланган көннән алып өч ел эчендә аларга язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт узганчы документлар кадрлар хезмәтендә саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

31. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән башкарыла.

32. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

2нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16нчы майның
163нче номерлы
карары белән расланды

# МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕ АТТЕСТАЦИЯЛӘҮНЕ УЗДЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 башлам. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге нигезләмә белән Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыруның гомуми тәртибе билгеләнә.

2. Аттестация муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килүен аның һөнәри эшчәнлеген бәяләү нигезендә билгеләү максатларында уздырыла.

Аттестация муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруга, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын кыскартканда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә өстенлекле хокукны билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү шартларын үзгәртүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә ярдәм итәчәк.

3. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестацияләнергә тиеш түгел:

1) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасында бер елдан кимрәк эшләгән затлар;

2) 60 яшькә җиткән;

3) йөкле хатыннар;

4) йөклелек һәм бала табу буенча ялда яисә бала карау буенча өч яшькә җиткәнче отпускта булучылар. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләрне отпусктан чыкканнан соң бер елдан соң гына аттестацияләү мөмкин;

5) сроклы хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүчеләр.

4. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү өч елга бер мәртәбә уздырыла.

## 2 башлам. АТТЕСТАЦИЯ УЗДЫРУНЫ ОЕШТЫРУ

5. Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча муниципаль берәмлек җирле үзидарә органының түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алган хокукый акты чыгарыла:

1) аттестация комиссиясе төзү турында;

2) аттестация үткәрү графигын раслау турында;

3) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләрнең исемлекләрен төзү турында;

4) бердәм аттестация комиссиясе эше өчен кирәкле документларны әзерләү турында (алга таба - комиссия).

6. Комиссия муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органының хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән комиссия составы, аның эшенең сроклары һәм тәртибе билгеләнә.

Комиссия составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләсе бүлекчәсеннән, юридик (хокукый) бүлекчәдән һәм аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торган бүлекчәдән), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында персональ мәгълүматларны күрсәтмичә чакырыла торган фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен комиссия составы дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.

7. Комиссия комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннан һәм әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия.

8. Аттестация үткәрү графигы ел саен яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан раслана һәм аттестация башланырга кимендә бер ай кала һәр муниципаль хезмәткәргә хәбәр ителә.

9. Аттестация үткәрү графигында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аттестация үткәрелә торган җирле үзидарә органы, бүлекчә исеме;

2) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

3) аттестация үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

4) аларның тапшырылуы өчен җаваплы булган муниципаль берәмлек җирле үзидарә органының тиешле бүлекчәләре җитәкчеләрен күрсәтеп, кирәкле документларны комиссиягә тапшыру датасы.

10. Аттестация башланырга ике атна кала аттестация узарга тиешле муниципаль хезмәткәрнең аттестация чорында вазыйфаи бурычларын үтәве турында комиссиягә турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм югарырак җитәкчесе раслаган бәяләмә тапшырыла.

11. Әлеге нигезләмәнең 10 пунктында каралган бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) аттестация үткәрү вакытына муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы һәм шушы вазыйфага билгеләнү датасы;

3) муниципаль хезмәткәр аларны хәл итүдә (эшләүдә) катнашкан төп мәсьәләләр (документлар) исемлеге;

4) муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатларын һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләрен дәлилләнгән бәяләү.

12. Аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр тарафыннан аттестация чорында вазыйфаи бурычларын үтәү турындагы бәяләмәгә муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге турында еллык хисапларда булган күрсәтелгән чорда муниципаль хезмәткәр тарафыннан үтәлгән йөкләмәләр һәм ул әзерләгән документлар проектлары турында белешмәләр кушып бирелә.

Аттестация комиссиясенә аннан соңгы һәр аттестация вакытында шулай ук муниципаль хезмәткәрнең алдагы аттестация күрсәткечләре белән аттестация кәгазе дә тапшырыла.

13. Аттестация башланырга кимендә биш эш көне кала җирле үзидарә органының муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бүлекчәсе аттестация башланырга кимендә биш эш көне кала аттестацияләнүче һәрбер муниципаль хезмәткәрне аттестация чоры өчен аның вазыйфаи бурычларын башкару турында тәкъдим ителгән бәяләмә белән таныштырырга тиеш. Шул ук вакытта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр аттестация комиссиясенә күрсәтелгән чорга үзенең һөнәри эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр, шулай ук тапшырылган бәяләмә белән риза булмавы турында яисә турыдан-туры җитәкчесенең бәяләмәсенә аңлатма бирү турында гариза тапшырырга хокуклы.

## 3 башлам. АТТЕСТАЦИЯНЕ УЗДЫРУ

14. Аттестация аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәрне комиссия утырышына чакырып уздырыла. Күрсәтелгән комиссия утырышына муниципаль хезмәткәр җитди сәбәпләрсез килмәгәндә яисә аның аттестацияләнүдән баш тарткан очракта муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә аттестация соңрак вакытка күчерелә.

Комиссия тапшырылган документларны карый, аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәрнең белешмәсен тыңлый, кирәк була калса - муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында аның турыдан-туры җитәкчесе хәбәрләрен тыңлый. Аттестацияне объектив үткәрү максатларында, аттестацияләнә торган муниципаль хезмәткәр аттестация чорында үзенең һөнәри эшчәнлеге турында тапшырган өстәмә белешмәләрне карарганнан соң, комиссия аттестацияне комиссиянең алдагы утырышына күчерергә хокуклы.

15. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм шәхси сыйфатларын аның һөнәри эшчәнлегенә карата фикер алышу объектив һәм яхшы мөгаләмәдә булырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге аның муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен билгеләү, аның тиешле бүлекчә (муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы) алдына куелган бурычларны хәл итүдә катнашуы, ул башкарган эшнең катлаулылыгы, аның эффективлыгы һәм нәтиҗәлелеге нигезендә бәяләнә.

Шул ук вакытта муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи инструкцияне үтәү нәтиҗәләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри белемнәре һәм эш тәҗрибәсе, муниципаль хезмәткәрләргә чикләүләрне үтәү, тыюларны бозулар булмау, муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән хезмәт тәртибен һәм йөкләмәләрне үтәү, ә башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-күрсәтмә вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрне аттестацияләгәндә, - шулай ук оештыру сәләте исәпкә алынырга тиеш.

16. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

17. Комиссия карары тикшерелә торган муниципаль хезмәткәр һәм аның турыдан-туры җитәкчесе булмаганда комиссия утырышында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең тиешле биләгән вазыйфасына туры килә дип танала.

Комиссия әгъзасы булган муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү чорына аның шушы комиссиядә әгъзалыгы туктатып торыла.

18. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә;

2) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

3) һөнәри яңадан әзерлек яисә квалификациясен күтәрү шартларында муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә;

4) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм чираттагы класслы чин бирелергә мөмкин;

5) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килми.

19. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгарганнан соң ук хәбәр ителә.

Аттестация нәтиҗәләре кушымта нигезендә форма буенча төзелгән муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазенә кертелә. Аттестация кәгазе утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

Муниципаль хезмәткәр аттестация кәгазе белән расписка астында танышырга мөмкин.

Аттестация узган муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазе һәм аттестация чорында аның вазыйфаи бурычларын башкару турында бәяләмә муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшендә саклана.

Комиссия секретаре комиссия утырышының протоколын алып бара, анда аның карарын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен теркәп бара. Комиссия утырышы беркетмәсенә утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары имза сала.

20. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү материаллары яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) аны уздырганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

21. Аттестация уздырганнан соң бер ай эчендә аның нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең хокукый акты бастырып чыгарыла яисә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең муниципаль хезмәткәр турында карары кабул ителә:

1) вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертелергә тиеш;

2) һөнәри яңадан әзерләүгә яисә квалификация күтәрүгә җибәрелә;

3) муниципаль хезмәт вазыйфасында түбәнәйтелә.

22. Муниципаль хезмәткәр һөнәри яңадан әзерләүдән, квалификация күтәрүдән яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерүдән баш тартканда, яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт

вазыйфасыннан азат итәргә һәм муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә муниципаль хезмәттән азат итәргә хокуклы.

Аттестация уздырганнан соң бер ай узгач, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү йә аны муниципаль хезмәттән әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча эштән азат итү рөхсәт ителми. Муниципаль хезмәткәрнең авыруы һәм еллык түләүле ялы вакыты күрсәтелгән вакытта исәпкә алынмый.

23. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация
уздыру турында нигезләмәгә
Кушымта

## МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕҢ АТТЕСТАЦИЯ КӘГАЗЕ

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ________________________________________
_____________________________________________________________________________

2. Туган елы, числосы һәм ае__________________________________________
_____________________________________________________________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме турында белешмәләр
_______________________________________________________________

(кайчан һәм кайсы уку йортын тәмамлаган,
_____________________________________________________________________________

Белеме буенча белгечлеге һәм квалификациясе,
_____________________________________________________________________________

гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме)

4. Аттестация вакытына биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм бу вазыйфага билгеләнгән датасы ___________________________________________
_____________________________________________________________________________

5. Муниципаль хезмәт стажы (шул исәптән дәүләт граждан хезмәте стажы)
__________________________________________________________

6. Гомуми хезмәт стажы __________________________________________________

7. Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыска җаваплар ________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

8. Аттестация комиссиясе әйткән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр _____
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

9. Муниципаль хезмәткәрнең алдагы аттестация рекомендацияләрен үтәвенә кыскача бәяләмә_____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)

10. Аттестация комиссиясе карары ____________________________________

(муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры
_____________________________________________________________________________

килә, муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш
_____________________________________________________________________________

тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен
_____________________________________________________________________________

билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;
_____________________________________________________________________________

һөнәри яңадан әзерлек яисә квалификациясен күтәрү шартларында
_____________________________________________________________________________

муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә;
_____________________________________________________________________________

муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килми)
_____________________________________________________________________________

11. Аттестация комиссиясенең сан ягыннан составы ____________________

Аттестация комиссиясенең ________әгъзасы утырышта катнашты.

Тавышларның саны: _________ әйе, _________ каршы.

12. Искәрмәләр ____________________________________________________________

Аттестация
комиссиясе рәисе _____________ ____________________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Аттестация комиссиясе
рәисенең урынбасары _____________ _________________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Аттестация
комиссиясе секретаре _____________ ________________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Аттестация
комиссиясе әгъзалары ______________ _______________________________________________________
(имза) (тулы имза)

______________ __________________________________________________
(имза) (тулы имза)

Аттестация уздыру датасы ________________________________________________________________

Аттестация кәгазе белән таныштым_________________________________________________________
___________________________________________________________________________________________
(муниципаль хезмәткәрнең имзасы, дата)

Мөһер урыны
(муниципаль берәмлекнең
җирле үзидарә органы)